ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18 март 2021ел № 1869

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары, шәһәр Уставының 42 статьясы, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘМ

1. Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 1 августындагы 4575 номерлы;

3) «Башкарма комитетның 2013 елның 1 августындагы 4575 номерлы карары белән расланган бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш

дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында турында» 2016 елның 28 июнендәге 3322 номерлы;

4) «Башкарма комитетның 2013 елның 1 августындагы 4575 номерлы карары белән расланган бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында турында» 2018 елның 28 апрелендәге 2399 номерлы;

5) «Башкарма комитетның 2013 елның 1 августындагы 4575 номерлы карары белән расланган бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында турында» 2018 елның 14 декабрендәге 7502 номерлы карары.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 18 мартындагы
1869 номерлы карарына
кушымта

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – регламент) бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

Әлеге регламент, аларны файдалануга тапшыру һәм дәүләт исәбенә кую Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә гамәлгә ашырылмаган капиталь төзелеш объектларында урнашкан торак урыннарга кагылмый.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: юридик һәм физик затлар – торак урыннар милекчеләре (наемга алучылар), бакча йортлары милекчеләре (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

Башкарма комитетның эш графигы:
дүшәмбе – җомга: 8.00 дән 17.00 гә кадәр.
шимбә, якшәмбе: ял көннәре.
Төшке аш: 12.00 дән 13.00 гә кадәр.
Белешмә телефоннары: (8552) 30-55-97, 30-59-51.
Керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтының адресы: http:// www.nabchelny.ru.

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат түбәндәге юл белән алынырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http://www.nabchelny.ru);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru) (алга таба – Региональ портал);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал);

5) Башкарма комитетта:

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – почта аша кәгазьдә, электрон почта kancel.chelny@tatar.ru аша электрон формада.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Башкарма комитет белгече тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Мәгълүмат стендларында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) бирелгән муниципаль хезмәт турында мәгълүматларны үз эченә ала.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актлар реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

торак урын – гражданнар яшәү өчен билгеләнгән аерым бүлмә, күчемсез милек булып тора һәм яшәү өчен яраклы;

торак урын дип танылa:

1) торак йорт – бүлмәләрдән, шулай ук гражданнарның анда яшәүгә бәйле көнкүреш һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән ярдәмче файдалану бүлмәләреннән торган индивидуаль-билгеләнгән бина;

2) фатир – күпфатирлы йортта әлеге йорттагы гомуми файдаланудагы бүлмәләргә турыдан-туры керү мөмкинлеген тәэмин итә торган һәм бер яки берничә бүлмәдән, шулай ук гражданнарның мондый аерым бинада яшәүгә бәйле көнкүреш һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән ярдәмче файдалану биналарыннан торган структур аерымланган бүлмә;

3) бүлмә – торак йортның яисә фатирның гражданнарның торак йортта яки фатирда турыдан-туры яшәү урыны буларак файдалану өчен билгеләнгән өлеше;

бакча йорты - гражданнарның мондый бинада аларның вакытлыча булуы белән бәйле көнкүреш һәм башка ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен билгеләнгән сезонлы файдалану бинасы;

күпфатирлы йорт – мөстәкыйль рәвештә йорт янындагы җир участогына яисә мондый йортта гомуми файдаланудагы биналарга чыгу мөмкинлеге булган ике һәм аннан күбрәк фатирлар җыелмасы. Күпфатирлы йортта торак законнары нигезендә мондый йорттагы бүлмә милекчеләренең гомуми милек элементлары бар;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры

килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Әлеге регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 пункт). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1, 2, 3 нче кушымталар).

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка карата таләпнең эчтәлеге | Муниципаль хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану | РФ Торак кодексының 14 статьясы 1 өлешенең 8 пункты<br>РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 7 пункты, 55 пункты |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтә торган җирле үзидарә башкару - боеру органының исеме | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты | Шәһәр Уставы |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында карар.<br>Торак урын яшәү өчен яраксыз дип танылган очракта – бүлмәне алга таба файдалану, йорт авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә дип танылган очракта физик һәм юридик затларны күчерү сроклары турында яки ремонт-торгызу эшләре үткәрү кирәклеген тану турында күрсәтелгән боерык.<br>Бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану яисә бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип танудан баш тарту турында карар (4 нче кушымта) | РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган нигезләмәнең 7 пункты<br>РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 59 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, әгәр туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | Торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану:<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срогы – гариза теркәлгән датадан башлап 30 календарь көн.<br>Комиссиянең чираттагы утырышын көтү муниципаль хезмәт күрсәтү срогына керми.<br>Бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану:<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срогы – гариза бирелгән көннән башлап 45 календарь көн.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату срогы каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документны бирү гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документны җибәрү гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын файдаланып (почта аша яки электрон адреска) муниципаль хезмәт нәтиҗәсе рәсмиләштерелгән һәм теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла | РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 46 пункты<br><br>РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 59 пункты |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе | Торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану өчен:<br>- гариза:<br>кәгазь документ рәвешендә;<br>электрон формада, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы яисә Региональ портал аша мөрәҗәгать иткәндә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзалана;<br>- аңа хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән торак урынга хокук билгели торган документларның күчермәләре;<br>- торак булмаган урынга карата, аны киләчәктә торак урын дип тану өчен - торак булмаган урынны реконструкцияләү проекты.<br>- күпфатирлы йортка тикшерү үткәргән махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе - күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану турында мәсьәлә куелган очракта; | РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 45 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | - торак урынның киртәләү һәм тотып торучы конструкцияләре элементларын тикшерү нәтиҗәләре буенча махсуслаштырылган оешмас бәяләмәсе – әгәр бәяләмә торак урынның Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен (туры килмәвен) тану турында карар кабул итү өчен кирәк булса.<br>Гариза бирүченең теләге буенча шулай ук яшәү шартлары канәгатьләнерлек булмау турында гражданнарның гаризалары, хатлары, шикаятьләре дә бирелергә мөмкин.<br>Бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану өчен:<br>- бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану турында гариза, анда бакча йорты яки торак йортның кадастр номеры һәм бакча йорты яки торак йорт урнашкан җир участогының кадастр номеры, гариза бирүченең почта адресы яки гариза бирүченең электрон почта адресы, шулай ук җирле үзидарәнең вәкаләтле органы карарын һәм нигезләмәдә каралган башка документларны алу ысулы күрсәтелә (тапшыру турында почта белдерү кәгазе, электрон почта, күпфункцияле үзәктә шәхсән алу, җирле үзидарәнең вәкаләтле органында шәхсән алу);<br>- гариза бирүченең бакча йортына яки торак йортка теркәлгән хокуклары турында мәгълүматларны үз эченә алган Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан күчемсез милек объектына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында өземтә (алга таба - Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә), яисә бакча йортына яки торак йортка милек хокукы Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән очракта, гариза бирүченең торак йортка яки бакча йортына хокукын билгеләүче документ яки мондый документның нотариуста расланган күчермәсе;<br>- бакча йортының 384 номерлы Федераль законның 5 статьясының 2 өлеше, 7, 8 һәм 10 статьяларында билгеләнгән ышанычлылык һәм куркынычсызлык таләпләренә туры килүен раслый торган объектның техник торышын тикшерү буенча | РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 56 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | бәяләмә, ул инженерлык эзләнүләре өлкәсендә үзен-үзе җайга салучы оешма әгъзалары булган шәхси эшмәкәр яки юридик зат тарафыннан бирелә;<br>- әгәр бакча йортына яки торак йортка өченче затларның да хокуклары булса, күрсәтелгән затларның бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тануга нотариаль расланган ризалыгы.<br>Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бланкын гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә Башкарма комитетта яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>почта аша.<br>Гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шулай ук гади электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында Бердәм портал, Региональ портал аша яки Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагында булган оешмалар | Торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану өчен:<br>1) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан торак урынга хокуклар турында мәгълүматлар;<br>2) торак урынның техник паспорты, ә торак булмаган урыннар өчен – техник план;<br>3) тиешле дәүләт күзәтчелеге (контроле) органнарының бәяләмәләре (актлары), әгәр бәяләмә бирү торак урынын | РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 45 (2) пункты |

| | | |
|---|---|---|
| карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килми дип тану турында карар кабул итү өчен кирәк булса.<br>Бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану өчен:<br>Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан күчемсез милек объектына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында өземтә.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән югарыда саналган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән мәгълүматлар булган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый. | РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 57 пункты |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) документлар тиешле булмаган зат тарафыннан бирелү;<br>2) тапшырылган документлар әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү;<br>3) гаризада һәм гаризага теркәлә торган документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңлатырга мөмкинлек бирми торган җитди кимчелекләр булу;<br>4) документларны тиешле булмаган органга тапшыру | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип танудан баш тарту өчен нигезләр:<br>- гариза бирүче тарафыннан документлар тулы булмаган күләмдә тапшырылган, яисә тапшырылган гаризада һәм (яки) | РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 33-40 пунктлары |

| | | |
|---|---|---|
| | документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат булу;<br>- әгәр тиешле документны гариза бирүче үз инициативасы белән бирмәгән булса, дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы яисә дәүләт хакимияте яки җирле үзидарә органының ведомство буйсынуындагы оешманың муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яисә) мәгълүмат булмауны дәлилләүче ведомствоара запроска җавабы керү;<br>- торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз), күпфатирлы йортны авария хәлендә, сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану өчен нигезләр булмау.<br>Бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип танудан баш тарту өчен нигезләр:<br>- гариза бирүче тарафыннан регламентның 2.5 пунктында каралган документлар тапшырылмау. Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә тапшырмау баш тарту өчен нигез булып тормый;<br>- җирле үзидарәнең вәкаләтле органына Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында гариза бирүче булмаган затның бакча йортына яки торак йортка милек хокукы теркәлүе турында мәгълүматлар керү;<br>- Нигезләмәнең 56 пунктындагы «б» пунктчасында каралган хокук билгеләүче документ яисә мондый документның нотариуста расланган күчермәсе гариза бирүче тарафыннан тапшырылмаган булса, җирле үзидарәнең вәкаләтле органына Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында бакча йортына яки торак йортка теркәлгән хокуклар турында мәгълүматлар булмау турында белдерү кәгазе керү. Әгәр җирле үзидарә органы Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында бакча йортына яки торак йортка теркәлгән хокуклар турында мәгълүматлар булмау турында белдерү кәгазе алганнан соң гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән мондый белдерү кәгазен алу турында хәбәр иткән, гариза бирүчегә Нигезләмәнең 56 пунктындагы «б» | РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 61 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | пунктчасында каралган хокук билгеләүче документ яки мондый документның нотариаль расланган күчермәсен тапшырырга тәкъдим иткән булса һәм хокук билгеләүче документ тапшыру турында белдерү кәгазе җибәргәннән соң 15 календарь көн эчендә гариза бирүчедән мондый документ яки мондый күчермәне алмаса, күрсәтелгән нигезләр буенча бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип танудан баш тартылырга мөмкин;<br>- бакча йортына яки торак йортка өченче затларның да хокуклары булганда, гариза бирүче тарафыннан 47 номерлы Нигезләмәнең 56 пунктындагы «г» пунктчасында каралган документ тапшырылмау;<br>- бакча йортын яки торак йортны Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану төрләре мондый урнаштыруны күздә тотмый торган җир участогында урнаштыру;<br>- гариза бирүче яки башка зат тарафыннан торак йортны даими яшәү урыны буларак файдалану (торак йортны бакча йорты дип тану турында гаризаны караганда). | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда, муниципаль хезмәттән файдалануга гариза бирү – 15 минуттан артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә<br>Ял (бәйрәм) көнне электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтеп тору залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрослар тутыру урыннарына, һәр муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документларны тутыру үрнәкләре | 1) муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган бүлмәләрдә һәм биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән | |

| | | |
|---|---|---|
| һәм исемлеге булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә таләпләр | мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.<br>2) инвалидларга тәэмин ителә:<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бинага, бүлмәгә тоткарлыксыз керү (керү һәм аннан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып);<br>- муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналар, бүлмәләр урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарда, бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;<br>- ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;<br>- закон нигезендә билгеләнә торган форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, бүлмәләргә юл күрсәтүче этне кертү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтә торган оешмаларның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә муниципаль хезмәттән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән таләпләр бары тик файдалануга яңа тапшырылган яки реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларга һәм чараларга гына куела. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләрен кулланып, гариза бирүче сайлавы буенча (экстерриториаль принцип) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (шул исәптән тулы күләмдә), җирле үзидарә органының теләсә кайсы башкару-боеру территориаль бүлекчәсендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрдә Федераль законның 15.1 статьясында каралган берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрослар (комплекслы запрос) ярдәмендә муниципаль хезмәттән файдалану мөмкинлеге яисә файдалана алмау | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:<br>Башкарма комитет бинасының җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында, Бердәм порталда муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга хезмәтләрдән башка затлар белән бертигез файдаланырга комачаулый торган каршылыкларны узарга ярдәм итү.<br><br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>гариза бирүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларны биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br><br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросны биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара хезмәттәшлек итүе күздә тотыла. Үзара хезмәттәшлекнең дәвамлылыгы регламент белән билгеләнә. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге сайтында, Бердәм порталда, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) алынырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы запрос составында күрсәтелми. | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең үзенчәлекләрен (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән булса) һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы таләпләр | Муниципаль хезмәтне электрон формада алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү яки Региональ портал аша алырга мөмкин.<br><br>Муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәткәндә гариза бирүче хокуклы:<br>1) Бердәм порталда яки Региональ порталда урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;<br>2) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон документ формасында региональ порталның «Шәхси кабинет»ыннан файдаланып гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән бирергә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны Региональ порталның «Шәхси кабинет»ы аша җибәргәндә көчәйтелгән квалификацион электрон имза файдаланыла. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы карарында каралган очракларда гариза бирүче гади электрон имза кулланырга хокуклы;<br>3) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында мәгълүматлар алырга;<br>4) Региональ портал аша муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 5) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;<br>6) Башкарма комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьне Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты, Региональ портал, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә башкарылган карарларга һәм эш итүләргә (эш итмәүләргә) судка кадәр шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша бирергә. | |

Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

Торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану өчен:

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) урында бүлмә карауны үткәрү һәм һәм акт рәсмиләштерү;

5) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

6) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

Бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану өчен:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

Торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен Башкарма комитетка шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Башкарма комитет белгече гариза бирүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен бирелә торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат яки КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша язмача яки электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирә һәм әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) тапшыра.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен ачыклауны;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч кәгазе буенча эш иткән очракта);

әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә каралган документларның булуын тикшерүне;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерүне.

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече

гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итүне һәм теркәүне;

гаризаны һәм теркәлгән документларны бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану мәсьәләләрен карап тикшерү буенча ведомствоара комиссия секретарена (алга таба – комиссия) җибәрүне.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең документлар кабул итүче белгече, гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

гаризаны һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, комиссия секретарена җибәрелгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.4. Ведомствоара запросларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү

3.4.1. Комиссия секретаре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада түбәндәгеләрне тапшыру турында запрос җибәрә:

1) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан торак урынга хокуклар турында мәгълүматлар;

2) торак урынның техник паспорты, ә торак булмаган урыннар өчен – техник план;

3) тиешле дәүләт күзәтчелеге (контроле) органнарының бәяләмәләре (актлары), әгәр дә бәяләмә бирү торак урынны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән расланган Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турындагы нигезләмәдә (алга таба – нигезләмә) билгеләнгән таләпләргә туры килүен (туры килмәвен) тану турында карар кабул итү өчен кирәк булса.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән запрослар.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрос нигезендә, соралган документларны (мәгълүматны) бирә яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында белдерү кәгазе (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе) җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар федераль законнарда билгеләнгән срокларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитетка җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.5. Бүлмәне урында карауны үткәрү һәм акт рәсмиләштерү

3.5.1. Гаризаны карап тикшерә торган комиссия секретаре муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булуны тикшерә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, комиссия секретаре гамәлгә ашыра:

документлар комплектлаштыруны (дело формалаштыруны);

документларны һәм комиссия утырышы беркетмәсе проектын (5 нче кушымта) карап тикшерү өчен, мәгълүмат-телекоммуникация элемтә челтәрләреннән файдаланып, комиссия әгъзаларына җибәрүне.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, комиссия секретаре гамәлгә ашыра:

комиссия утырышы беркетмәсе проектларын һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында бәяләмә әзерләүне;

мәгълүмат-телекоммуникацион элемтә челтәрләреннән файдаланып, документларны комиссия әгъзаларына җибәрүне.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар запросларга җавап алынган вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: комиссия әгъзаларына җибәрелгән документлар.

3.5.2. Комиссия:

торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында гаризаны карап тикшерә;

бүлмәнең Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяли;

комиссия утырышы беркетмәсе проектын карап тикшерә;

әлеге регламентның 2.8 пунктында каралган муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булганда, алар булу турында карар чыгара;

бүлмәне урында карау һәм бүлмәне тикшерү актын рәсмиләштерү кирәклеген билгели.

Бүлмәне карау кирәк булмаган очракта, комиссия торак урынны яшәү өчен яраклы дип тану (танудан баш тарту) турында карар кабул итә, ул комиссия утырышы беркетмәсендә билгеләп куела.

Бүлмәне урында карау һәм бүлмәне тикшерү актын рәсмиләштерү зарурилыгы булган очракта, комиссия әгъзалары әлеге регламентның 3.5.4 пунктчасында каралган процедураларны гамәлгә ашыра. Торак урынны яшәү өчен яраклы дип тану (танудан баш тарту) мөмкинлеге турында карар тикшерү актын рәсмиләштергәннән соң кабул ителә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура утырыш көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип танудан баш тарту турында карар яисә бүлмәне урында карау кирәклеге турында карар.

3.5.3. Комиссия секретаре бүлмәне карап чыгарга җәлеп ителә торган экспертлар составын һәм карап чыгу датасын билгели. Комиссия әгъзалары, гариза бирүче һәм экспертларга карап чыгу датасы хәбәр ителә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура комиссия тарафыннан бүлмәне карау турында карар чыгарылган вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия әгъзаларына, гариза бирүчегә һәм экспертларга карау датасы турында хәбәр итү.

3.5.4. Билгеләнгән көнне комиссия урынга чыга һәм экспертлар һәм гариза бирүче катнашында бүлмәне тикшерә. Тикшерү нәтиҗәләре буенча бүлмәне тикшерү акты төзелә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар бүлмәне карау көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлмәне тикшерү акты (6 нчы кушымта).

3.5.5. Комиссия секретаре, әлеге регламентның 3.5.1 пунктында билгеләнгән тәртиптә, бүлмәне тикшерү актын һәм комиссия утырышы беркетмәсе проектын карап тикшерү өчен комиссиягә чыгара.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура бүлмәне тикшергән вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия карап тикшерүенә чыгарылган бүлмәне тикшерү акты.

3.5.6. Комиссия:

бүлмәне тикшерү актын һәм комиссия утырышы беркетмәсе проектын карап тикшерә;

карар чыгара, ул беркетмәдә билгеләп куела.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия әгъзалары тарафыннан карап тикшерелгән документлар.

3.5.7. Комиссия беркетмәсе нигезендә, комиссия секретаре комиссия карарын бәяләмә (7 нче кушымта) рәвешендә 3 нөсхәдә рәсмиләштерә һәм имзалау өчен кәгазьдә комиссия әгъзаларына җибәрә.

Әлеге Регламентның 3.5.6, 3.5.7 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар 3.5.5 пунктчада каралган процедура тәмамланганнан вакыттан башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган бәяләмә.

3.5.8. Комиссия секретаре имзаланган бәяләмәне раслау өчен комиссия рәисенә – Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: раслау өчен җибәрелгән бәяләмә.

3.5.9. Комиссия рәисе бәяләмәне раслый һәм Башкарма комитет белгеченә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган һәм Башкарма комитет белгеченә җибәрелгән бәяләмә.

Әлеге Регламентның 3.5.8-3.5.9 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар 3.5.7 пунктчада каралган процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.6. Муниципаль хезмәт нәтиҗәләрен әзерләү

3.6.1. Башкарма комитет белгече бәяләмә нигезендә:

торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында Башкарма комитет карары проектын яисә торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану турында боерык проектын әзерли. Боерык проектында торак урыннан алга таба файдалану тәртибе, физик һәм юридик затларны күчерү сроклары күрсәтелә;

билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән документ проектын килештерү процедурасын гамәлгә ашыра;

документ проектын имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура комиссия бәяләмәсе кергән вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесенә имзалау өчен җибәрелгән карар (боерык) проектлары.

3.6.2. Башкарма комитет Җитәкчесе карарны (боерыкны) имзалый, ул теркәү өчен эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура проектлар кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәү өчен җибәрелгән карар (боерык).

3.7. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.7.1. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече:

карарны (боерыкны) терки;

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә карар кабул

ителгән көннән башлап биш көннән дә соңга калмыйча, рәсмиләштерелгән карарны бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итү.

3.7.2. Башкарма комитет белгече карарны (боерыкны) гариза бирүчегә (аның вәкиленә) бирә.

Гариза бирүче нәтиҗәне электрон төрдә алу ысулын сайлаганда, гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен электрон документ формасында җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар бәяләмә расланган көннән башлап биш көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән бәяләмә һәм карар (боерык).

Бакча йортын торак йорт яки торак йорны бакча йорты дип тану

3.8. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.8.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен Башкарма комитетка шәхсән, телефон аша һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Башкарма комитет белгече гариза бирүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен бирелә торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә һәм кирәк булганда гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм рөхсәт алуның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.9. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.9.1. Гариза бирүче шәхсән, ышанычлы зат яки КФҮ, КФҮнең ерактагы эш урыны аша язма яки электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирә һәм әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә тапшыра.

3.9.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен ачыклауны;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч язуы буенча эш иткәндә);

әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә каралган документларның булуын тикшерүне;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен.

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итүне һәм теркәүне;

аларның исемлеген һәм алу датасын күрсәтеп, гариза бирүчедән документлар алу турында расписка бирүне. Гариза бирүче тарафыннан документлар күпфункцияле үзәк аша тапшырылган очракта, расписка күпфункцияле үзәк тарафыннан бирелә;

гаризаны һәм теркәлгән документларны комиссия секретарена җибәрүне.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең документлар кабул итүче белгече, гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул

итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

гаризаны һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, комиссия секретарена җибәрелгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.10. Ведомствоара запросларны формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.10.1. Комиссия секретаре ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада торак урынга хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан мәгълүматлар бирү турында запрос җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән запрослар.

3.10.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, соралган документларны (мәгълүматны) бирә яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында белдерү кәгазе (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе) җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар биш эш көненнән артмаган срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Башкарма комитетка җибәрелгән документлар (мәгълүматлар) яисә баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.11. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.11.1. Кергән документларны карап тикшергәннән соң комиссия секретаре гамәлгә ашыра:

документлар комплектлаштыруны (дело формалаштыруны);

документларны һәм комиссия утырышы беркетмәсе проектын (5 нче кушымта) карап тикшерү өчен, мәгълүмат-телекоммуникация элемтә челтәрләреннән файдаланып, комиссия әгъзаларына җибәрүне.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура документлар кергән вакыттан башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: комиссия әгъзаларына җибәрелгән документлар.

3.11.2. Комиссия:

бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану турында гаризаны карап тикшерә;

комиссия утырышы беркетмәсе проектын карап тикшерә;

алар булганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу турында карар чыгара;

муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану турында карар кабул итә, ул комиссия утырышы беркетмәсендә билгеләп куела.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар документлар карап тикшерү өчен комиссия әгъзаларына кергән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: комиссия әгъзалары тарафыннан карап тикшерелгән документлар.

3.11.3. Комиссия беркетмәсе нигезендә комиссия секретаре:

бакча йортын торак йорт яки торак йортны бакча йорты дип тану турында (танудан баш тарту турында) карар әзерли;

карарны раслау өчен комиссия рәисенә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура документлар комиссия әгъзалары тарафыннан карап тикшерелгән вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән карар.

3.11.4. Комиссия рәисе, теркәү өчен Башкарма комитет белгеченә җибәрелә торган карарны раслый.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура карар кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм теркәү өчен җибәрелгән карар.

3.12. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү

3.12.1. Башкарма комитет белгече гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә һәм карарны гариза бирүченең кулына тапшыра яисә гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә җибәрелгән карар.

3.13. Техник хаталарны төзәтү

3.13.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып исәпләнә торган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Башкарма комитетка түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (8 нче кушымта);

гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

юридик көчкә ия һәм техник хата булуны таныклаучы документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып), яисә Бердәм портал яки КФҮ аша тапшырыла.

3.13.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең документларны кабул итү өчен җаваплы белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, теркәлгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны Башкарма комитетка тапшыра.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет белгеченә җибәрелгән гариза.

3.13.3. Башкарма комитет белгече документларны карап тикшерә һәм хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатында әлеге регламентның 3.6 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм техник хата булган документның төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алгач, шәхсән имза куйдырып, төзәтелгән документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки почта аша (электрон почта аша) гариза бирүченең адресына, техник хата булган документның төп нөсхәсен Башкарма комитетка тапшырган очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан яки җибәрелгән хата турында теләсә кайсы кызыксынган зат тарафыннан гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозуны ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешен тикшерүне, Башкарма комитет вазыйфаи затларының эш итүләренә (эш итмәүләренә) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш кәгазьләрен алып баруга карата билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүматлар базасында булган мәгълүматлар, хезмәт корреспонденциясе, административ процедураларны башкаручы белгечләрнең телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка мәгълүматлар файдаланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә эш итүләрне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр бирелә.

Административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында белгечләр кичекмәстән Башкарма комитет Җитәкчесенә хәбәр итәләр, шулай ук кимчелекләрне бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеге Башкарма комитетның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи инструкцияләр нигезендә билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында карап тикшерелмәве өчен җаваплы.

Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары әлеге регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул иткән (гамәлгә ашырган) карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Башкарма комитетның, КФҮнең, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең һәм хезмәткәрләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең эш итүләренә (эш итмәүләренә) - Башкарма комитетка, КФҮ хезмәткәрләре буенча – КФҮгә яисә КФҮне гамәлгә куючы тиешле дәүләт хакимияте органына судка кадәр тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу (берничә муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос белән КФҮ аша мөрәҗәгать иткәндә);

2) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

5) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

6) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

7) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

8) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

10) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату, әгәр туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта;

11) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп итү.

5.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның җитәкчесенең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан

(http://www.nabchelny.ru), Региональ порталдан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм порталдан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә алынырга мөмкин.

5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, яисә югарыдыгы органга (ул булганда) кергән шикаять ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылуга шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәвенә) шикаять бирелә торган хезмәт күрсәтүче органның, хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче – юридик затның исеме, урнашу урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең шикаять бирелә торган карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) турында мәгълүмат;

4) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки муниципаль хезмәткәрнең карарлары һәм эш итүләре (эш итмәүләре) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлгән документлар исемлеге язып куела.

Шикаять аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы тарафыннан имзалана.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында Башкарма комитет, КФҮ яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта җитешсезлекне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.

Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук КФҮнең, КФҮ белгеченең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы

А.Ф. Бареева

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану мәсьәләләрен карап тикшерү буенча ведомствоара комиссиягә

______________________________________
адресы буенча яшәүче
______________________________________

Бүлмәнең билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләүне үткәрү һәм торак урынны яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану турында
гариза

Мин, __________________________________________________________,
______________________________________________________________
адресы буенча урнашкан торак урынның ________________________ булып торам, бу
(милекчесе, наемга алучысы)
______________________________________________________ белән раслана.
(милеккә хокук таныклыгы, наем килешүе)
____________________________ нигезендә, әлеге торак урынның милекчесе булып
____________________________ тора (әгәр гариза наемга алучы тарафыннан бирелсә).

Әлеге торак урынның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карарында күздә тотылган таләпләргә туры килүен бәяләү үткәрүне һәм торак урынны түбәндәге нигезләргә бәйле рәвештә яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тануны сорыйм:

__________________________________________________________
__________________________________________________________
__________________________________________________________.

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) аңа хокук Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән торак урынга хокук билгеләүче документларның күчермәләре;

2) торак булмаган урынга карата аны алга таба торак урын дип тану өчен – торак булмаган урынның реконструкция проекты;

3) күпфатирлы йортка тикшерү үткәргән махсуслаштырылган оешма бәяләмәсе - күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану мәсьәләсе куелган очракта;

4) торак урынның киртәләү һәм тотып торучы конструкцияләре элементларын тикшерү нәтиҗәләре буенча проект-тикшеренү оешмасы бәяләмәсе, әгәр бәяләмә торак урынның Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килүен (туры килмәвен) тану турында карар кабул итү өчен кирәк булган очракта.

Запрос соралганда сканерланган документларның төп нөсхәләрен тапшырырга йөкләмә алам.

«____»________________ _____ ел ____________________

(имза)

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитет
Җитәкчесенә

____________________________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме

____________________________________
____________________________________
____________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы)

Бакча йортын торак йорт дип тану турында
гариза

______________________________________________________________________урнашкан,
(почта адресы күрсәтелә)
кадастр номеры ____________________ булган бакча йортын торак йорт дип тануны сорыйм,

җир участогының кадастр номеры ____________________________________
(кадастр номеры күрсәтелә)

Гаризага теркәлә:
1. __________________________________________________________________________
2. __________________________________________________________________________
3. __________________________________________________________________________
4. __________________________________________________________________________

Торак йортны бакча йорты дип тану турында карарны һәм башка документларны түбәндәге ысул белән алырга телим:

| | |
|---|---|
| электрон почта адресына | ☐ |
| шәхсән җирле үзидарә органында | ☐ |
| дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк аша | ☐ |
| почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе белән | ☐ |

Моның белән «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү йөзеннән, минем персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм. Мин персональ мәгълүматларны эшкәртү дигәндә автоматлаштыру чараларын файдаланып яки андый чаралардан файдаланмыйча, персональ мәгълүматларны җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), өземтә алу, файдалану, тапшыру (тарату, бирү, файдаланырга рөхсәт алу), шәхси үзенчәлекләрен бетерү, блокировкалау, бетерү, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруны да кертеп, персональ мәгълүматлар белән теләсә нинди эш итү (операция) яки эш итүләр (операцияләр) җыелмасы күздә тотылуы турында хәбәрдар һәм аңлыйм.

Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: ___________________.

| | | |
|---|---|---|
| ________________________________ | _________________ | «____» ________ 20____ ел |
| Гариза бирүченең (вәкилнең) Ф.И.А.и. | (имза) | |

Документларны алу турында расписка алдым

| | | |
|---|---|---|
| «___» _____ 20__ел | __________________________ | __________________________ |
| | гариза бирүченең (вәкилнең) имзасы | гариза бирүченең (вәкилнең) Ф.И.А. и. |

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитет
Җитәкчесенә

___________________________________
(фамилияс, исеме, атасының исеме)
___________________________________
___________________________________
___________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы)

Торак йортны бакча йорты дип тану турында
гариза

_____________________________________________________________________урнашкан,
(почта адресы күрсәтелә)
кадастр номеры ___________________ булган торак йортны бакча йорты дип тануны сорыйм,

җир участогының кадастр номеры __________________________________
(кадастр номеры күрсәтелә)

Гаризага теркәлә:
1. ______________________________________________________________
2. ______________________________________________________________
3. ______________________________________________________________
4. ______________________________________________________________

Торак йортны бакча йорты дип тану (тануны кире кагу) турында карарны һәм башка документларны түбәндәге ысул белән алырга телим:

| | |
|---|---|
| электрон почта адресына | |
| шәхсән җирле үзидарә органында | |
| дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк аша | |
| почта аша тапшыру турында белдерү кәгазе белән | |

Моның белән «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү йөзеннән, минем персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм. Мин персональ мәгълүматларны эшкәртү

дигәндә автоматлаштыру чараларын файдаланып яки андый чаралардан файдаланмыйча, персональ мәгълүматларны җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), өземтә алу, файдалану, тапшыру (тарату, бирү, файдаланырлык булу), шәхси үзенчәлекләрен бетерү, блокировкалау, бетерү, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруны да кертеп, персональ мәгълүматлар белән теләсә нинди эш итү (операция) яки эш итүләр (операцияләр) җыелмасы күздә тотылуы турында хәбәрдар һәм аңлыйм.

Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: __________________.

| | | |
|---|---|---|
| ______________________________ | ________________ | «____» ________ 20____ ел |
| Гариза бирүченең (вәкилнең) Ф.И.А.и. | (имза) | |

Документларны алу турында расписка алдым

| | | |
|---|---|---|
| «___» _____ 20__ел | _________________________ | __________________________ |
| | гариза бирүченең (вәкилнең) имзасы | гариза бирүченең (вәкилнең) Ф.И.А. и. |

Бүлмәне торак урын, торак урынны
яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы
йортны авария хәлендә һәм сүтелергә
яки реконструкцияләнергә тиеш,
бакча йортын торак йорт һәм торак
йортны бакча йорты дип тану буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Бакча йортын торак йорт
һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында
КАРАР
дата, номер

______________________________________________________________________
(гариза бирүче физик затның ф.и.а.и., юридик затның - исеме)

______________________________________________________________________
адресы буенча урнашкан, кадастр номеры ____________________булган җир участогы чикләрендә урнашкан бакча йортын торак йорт/ торак йортны бакча йорты дип тану
(кирәк булмаганын сызарга)
______________________________________________________________________
теләге белән мөрәҗәгать итүе сәбәпле,

______________________________________________________________________

______________________________________________________________ нигезендә
(хокук билгеләүче документның исеме һәм реквизитлары)

______________________________________________________________________

тапшырылган документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул ителде:

______________________________________________________________
(бакча йортын торак йорт дип/торак йортны бакча йорты дип – кирәклесен күрсәтергә)
танырга.

____________________________
(вазыйфа)

________________________________ ________________________________
(Башкарма комитет вазыйфаи затының Ф.И.А.и.) (Башкарма комитеты вазыйфаи затының имзасы)

М.У.
(карарны шәхсән алган очракта тутырыла)

Алдым: «____» ____________ 20___ ел ______________________
(гариза бирүченең имзасы )

Карар гариза бирүче адресына җибәрелде «____» ______________ 20____ ел
(карар почта аша җибәрелгән очракта тутырыла)

______________________________________________________________________
(карарны гариза бирүче адресына җибәргән вазыйфаи затның Ф.И.А.и., имзасы)

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану мәсьәләләрен карап тикшерү буенча ведомствоара комиссия утырышының
беркетмәсе

«____» ____________20___ ел                                                            Яр Чаллы шәһәре

Түбәндәге составтагы комиссия:
- ;
- ;
- …

<u>Көн тәртибе:</u>

1. Гариза бирүче:
2. Мәсьәләнең характеры

<u>Көн тәртибе буенча мәгълүмат:</u>

<u>Искәрмә:</u>

Тавыш бирү:

| Комиссия әгъзалары | <u>Риза/Каршы</u> |
|---|---|
| - | |
| - | |
| - | |
| - | |
| - | |
| - | |

Ведомствоара комиссия бәяләмәсе/карары: ________________________________________ …

Ведомствоара комиссия рәисе ________________________________________________ …

Ведомствоара комиссия секретаре ____________________________________________ …

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
6 нчы кушымта

Бүлмәне тикшерү
акты

№ ________________________________ ____________________________________________
(дата)

______________________________________________________________________________
(бүлмәнең урнашу урыны, шул исәптән,
торак пункт һәм урам исеме, йорт һәм фатир номеры)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 22 июнендәге 3784 номерлы карары белән төзелгән бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану мәсьәләләрен карап тикшерү буенча ведомствоара комиссия

рәис __________________________________________________________________________
(ф.и.а.и., вазыйфасы һәм эш урыны)

комиссия әгъзалары _________________________________________________ составында
(ф.и.а.и., вазыйфасы һәм эш урыны)

чакырылган экспертлар ______________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(ф.и.а.и., вазыйфасы һәм эш урыны)

һәм чакырылган торак милекчесе яки аның вәкаләтле заты катнашында _______________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(ф.и.а.и.,вазыйфасы һәм эш урыны)

______________________________________________________________________________
(гариза бирүченең реквизитлары: ф.и.а.и. һәм адресы - физик зат өчен, оешманың исеме һәм вазыйфасы - юридик зат өчен)

гаризасы буенча түбәндәге бүлмәгә тикшерү үткәрде һәм әлеге бүлмәне тикшерү акты төзеде: _____________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________.
(бүлмәнең адресы, кемнеке булуы, кадастр номеры, файдалануга тапшыру елы)

Торак урынның, бинаның инженерлык системалары, җиһазлар һәм механизмнарның һәм бина янындагы территориянең торышына кыскача тасвирлама
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________.

Билгеләнгән таләпләргә туры килмәү турында мәгълүматлар, күрсәткечнең фактлагы зурлыклары яки конкрет туры килмәүнең тасвирламасы белән ____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________.

Үткәрелгән инструменталь контроль һәм тикшеренүләрнең башка төрләре нәтиҗәләрен бәяләү ____________________________________________________________
____________________________________________________________.
(контроль (сынау) кем тарафыннан үткәрелгән, нинди күрсәткечләр буенча, нинди фактлагы зурлыклар алынган)

Ведомствоара комиссия рекомендацияләре һәм даими яшәү өчен куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм нормаль шартлар тудыру өчен кабул ителергә тиешле тәкъдим ителә торган чаралар____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________.

Бүлмәне тикшерү нәтиҗәләре буенча ведомствоара комиссия бәяләмәсе ____________________________________________________________
____________________________________________________________
____________________________________________________________

____________________________________________________________.

Актка кушымта:
а) инструменталь контроль нәтиҗәләре;
б) лаборатор сынаулар нәтиҗәләре;
в) тикшеренүләр нәтиҗәләре;
г) проект-эзләнү һәм махсуслаштырылган оешмалар экспертларының бәяләмәләре;
д) ведомствоара комиссиянең карарлары буенча башка материаллар.

Ведомствоара комиссия рәисе

____________________________________________________________
(имза) (ф.и.а.и.)

Ведомствоара комиссия әгъзалары

______________________ ______________________
(имза) (ф.и.а.и.)

______________________ ______________________
(имза) (ф.и.а.и.)

______________________ ______________________
(имза) (ф.и.а.и.)

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
7 нче кушымта

Торак урынны даими яшәү өчен
яраклы (яраксыз) дип тану турында
бәяләмә

№ ______________________________ ____________________________
(дата)

____________________________________________________________________________
(бүлмәнең урнашу урыны, шул исәптән торак пункт һәм урам исеме, йорт һәм фатир номеры)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның июнендәге 3784 номерлы карары белән төзелгән бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану мәсьәләләрен карап тикшерү буенча ведомствоара комиссия

рәис ______________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., вазыйфасы һәм эш урыны)

комиссия әгъзалары _______________________________________________ составында
(Ф.И.А.и., вазыйфасы һәм эш урыны)

чакырылган экспертлар ______________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., вазыйфасы һәм эш урыны)

һәм чакырылган торак милекчесе яки аның вәкаләтле заты катнашында
___________________________________________________________________________,
(Ф.И.А.и., вазыйфасы һәм эш урыны)

карап тикшерелгән документлар нәтиҗәләре_______________________________________
(документлар исемлеге бирелә)

____________________________________________________________________________

һәм ведомствоара комиссиянең тикшерү нәтиҗәләре буенча төзелгән акты нигезендә

____________________________________________________________________________
(тикшерү актыннан алынган бәяләмә күрсәтелә (тикшерү үткәрелгән очракта),

____________________________________________________________________________
яки ведомствоара комиссия карары нигезендә тикшерү үткәрелмәве күрсәтелә)

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

______________________________________________________________________
(ведомствоара комиссия тарафыннан бүлмәнең торак бүлмәгә карата куела

______________________________________________________________________
торган таләпләргә туры килүен һәм аның даими яшәү өчен яраклы (яраксыз)

______________________________________________________________________
булуын бәяләү турында кабул ителгән бәяләмәсенең нигезләре китерелә)

______________________________________________________________________.
турында карар кабул итте.

Бәяләмәгә кушымта:
а) карап тикшерелгән документлар исемлеге;
б) бүлмәне тикшерү акты (тикшерү үткәргән очракта);
в) ведомствоара комиссия тарафыннан соралган башка материалларның исемлеге;
г) ведомствоара комиссия әгъзаларының аерым фикере:
______________________________________________________________________.

Ведомствоара комиссия рәисе

| _____________________ | _____________________________ |
|---|---|
| (имза) | (Ф.И.А.и.) |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| _____________________ | _____________________________ |
|---|---|
| (имза) | (Ф.И.А.и.) |
| _____________________ | _____________________________ |
| (имза) | (Ф.И.а.и.) |

Бүлмәне торак урын, торак урынны
яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы
йортны авария хәлендә һәм сүтелергә
яки реконструкцияләнергә тиеш,
бакча йортын торак йорт һәм торак
йортны бакча йорты дип тану буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
8 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
________________________________

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

________________________________________________________________
(хезмәтнең исеме)
муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган: ________________________________________________________
_____________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: ________________________________________________
________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail: ______________________ адресына җибәрү юлы белән;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне: _____________________________________________________________________.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: __________________.

_______________ ___________________ (___________________________)

(дата) (имза) (Ф. И. А.и.)

Бүлмәне торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | |
| Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе | 30-55-51 | kancel.chelny@tatar.ru |
| Комиссия секретаре | 30-59-51 | Ik414@mail.ru |